КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 24 июнь г.Казань № 453

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы; 2006 ел, 19 июнь, 312 нче; 2010 ел, 31 май, 419 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы; 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы; 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы; 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы; 2013 ел, 19 март, 185 нче; 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы; 2016 ел, 19 март, 150 нче; 2016 ел, 29 октябрь, 796 нчы; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 18 декабрь, 1008 нче; 2018 ел, 22 март, 161 нче; 2018 ел, 5 июнь, 430 нчы; 2018 ел, 17 декабрь, 1155 нче; 2019 ел, 16 март, 185 нче; 2019 ел, 22 июль, 613 нче; 2020 ел, 11 февраль, 99 нчы; 2020 ел, 11 июль, 575 нче; 2020 ел, 19 август, 710 нчы; 2021 ел, 21 гыйнвар, 19 нчы; 2021 ел, 18 июнь, 476 нчы; 2021 ел, 6 декабрь, 1168 нче; 2022 ел, 22 апрель, 389 нчы; 2022 ел, 1 июнь, 511 нче; 2022 ел, 18 август, 852 нче; 2022 ел, 2 сентябрь, 946 нчы; 2022 ел, 1 ноябрь, 1165 нче; 2022 ел, 5 декабрь, 1288 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1485 нче; 2023 ел, 12 апрель, 451 нче; 2023 ел, 9 июнь, 704 нче; 2023 ел, 2 август, 936 нчы; 2023 ел, 31 август, 1058 нче; 2024 ел, 20 май, 339 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

сиксән тугызынчы абзацта:

татар текстында «, конкурс документациясен раслый» сүзләрен өстәргә;

«йөртүчеләр» сүзен төшереп калдырырга;

туксанынчы абзацта «төбәкара һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

туксан беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның $3^5$ статьясындагы 4 пункты һәм 6 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы чикләрендә узучы халыкара һәм регионара даими йөртү маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган транспорт чараларының экологик тасвирнамәләренә карата таләпләр билгели;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан автомобиль юлларында һәм урам-юл челтәрендә автомат режимда эшли торган, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны теркәү өчен фотога һәм кинога төшерү, видеога яздыру функцияләре булган стационар махсус техник чараларны, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны теркәү өчен фотога һәм кинога төшерү, видеога яздыру функцияләре булган күчмә махсус техник чараларны һәм (яки) юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны теркәү өчен фотога һәм кинога төшерү, видеога яздыру функцияләре булган мобиль махсус техник чараларны (алга таба шул ук эзлеклелектә – стационар теркәү чарасы, күчмә теркәү чарасы, мобиль теркәү чарасы) урнаштыру (куллану) турында карар кабул итә;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан автомобиль юлларында һәм урам-юл челтәрендә урнашкан һәм (яисә) файдаланыла торган, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны теркәү өчен автомат режимда эшли торган стационар, күчмә, мобиль махсус техник чараларны сүндерү (файдаланмау) турында һәм сүтеп алу турында карар кабул итә;

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның $22^1$ статьясы нигезендә стационар теркәү чараларын, күчмә теркәү чараларын һәм (яки) мобиль теркәү чараларын сүндерү (файдаланмау) турында һәм (яки) сүтеп алу турындагы карарны килештерә;

даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасы дубликатын бирү тәртибен билгели, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасы дубликатын бирә.».

8. Бу карар, әлеге карарның рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә торган 1 пунктындагы алтынчы абзацыннан тыш, 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин